**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 1 феврале** **№ 29**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе һәм административ комиссиясе турында» муниципаль район Советының 2006 елның 15 декабрендәге 93 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетын административ комиссия төзүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
3. Кама Тамагы муниципаль районының башкарма комитетына:
   3.1. Административ комиссия төзергә;
   3.2. Административ комиссия составын расларга;
   3.3. Административ комиссия эше регламентын расларга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Башлыгы, Кама Тамагы муниципаль район**
**Советы рәисе** **Н.А.Вазыйхов**